**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

422750, село Большая Атня,
улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы,
Совет урамы,38нче йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13 сентябрь 2024ел. № 407

**Әтнә районы Башкарма комитетының «Әтнә муниципаль районында гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү һәм коткару хезмәтләрен булдыру турында»05.05.2021 №120 карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында»гы 12.03.2024 ел, № 288 карары нигезендә Әтнә район башкарма комитеты карар бирә:

1. Әтнә районы Башкарма комитетының «Әтнә муниципаль районында гражданнар оборонасы һәм коткару хезмәтләрен булдыру чараларын тәэмин итү турында»гы 05.05.2021ел, №120 карарына (алга таба Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карар белән расланган Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районында коткару хезмәтләрен булдыру һәм аларның эшчәнлекләрен гамәлгә ашыру тәртибенең 3нче бүлек 2.1 пунктының 2нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- халыкка хәбәр итү системаларын, шул исәптән муниципаль һәм локаль хәбәр итү системаларын төзү, реконструкцияләү һәм файдалануга даими әзерлек халәтендә тоту;»;

1.2. Карар белән расланган Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районында коткару хезмәтләрен булдыру һәм аларның эшчәнлекләрен гамәлгә ашыру тәртибенең 3нче бүлек 2.1 пунктының 3нче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

1.3. Карар белән расланган Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районында гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү турында нигезләмәнең 4.2 нче пунктның 2 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- халыкка хәбәр итү системаларын, шул исәптән муниципаль һәм локаль хәбәр итү системаларын төзү, реконструкцияләү һәм файдалануга даими әзерлек халәтендә тоту;».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында (https://atnya.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җитәкче А. Ф. Каюмов